ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
от 31.07.2015

г. Казань

**КАРАР**
№ 10-18/кс

***"Менделеевск районы торак-комуналь хуҗалыгы идарәсе" муниципаль коммуналь предприятиясе өчен эчергә яраклы суга һәм ташландык суларны транспортировкалауга тарифлар билгеләү турында***

«Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ санлы Федераль законга, «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүче һәм ташландык суларны транпортировкалауны башкаручы "Менделеевск районы торак-комуналь хуҗалыгы идарәсе" муниципаль коммуналь предприятиясе өчен эчергә яраклы суга һәм ташландык суларны транспортировкалауга тарифларны элеге карар кушымтасы нигезендә билгеләргә.
2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2015 елның 1 сентябреннән 2015 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.
3. Салкын су белән тәэмин итүче һәм ташландык суларны транпортировкалауны башкаручы "Менделеевск районы торак-комуналь хуҗалыгы идарәсе" муниципаль коммуналь предприятиясенә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 санлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән алып 30 календарь көннән дә соңга калмыйча халыкка җиткерелергә тиешле мәгълүматны ачарга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты Рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасының
тарифлар буенча Дәүләт комитеты
карарына кушымта
31.07.2015 № 10-18/кс

Салкын су белән тәэмин итүче һәм ташландык суларны транпортировкалауны башкаручы “Менделеевск районы торак-комуналь хуҗалыгы идарәсе” муниципаль коммуналь предприятиясе өчен эчергә яраклы суга һәм ташландык суларны транспортировкалауга тарифлар

| № п/п | Салкын су белән тәэмин итүче һәм (яисә) су агызуны башкаручы оешмалар, муниципаль берәмлекләр атамасы | Эчәргә яраклы суга тариф (бер ставкалы) сум/куб. | Тариф на транспортировку сточных вод (одноставочный), руб./куб.м |
|---|---|---|---|
| | Менделеевск муниципаль районы | | |
| 1 | “Менделеевск районы торак-комуналь хуҗалыгы идарәсе” муниципаль коммуналь предприятиясе* | | |
| 1.1 | Абалач, Бизяк, Брөшли, Енабердино, Камай, Монашево, Псэй, Иске Гришкино, Татар Чаллысы, Тойгуҗа, Турай авыл җирлекләре | 22,18 | |
| 1.2 | Ижевка авыл җирлеге кулланучылары | 22,18 | 14,57 |
| 1.3 | Мунайка авыл җирлеге кулланучылары | 31,73 | |

<*> салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана